**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Мордва Кармалка торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 29 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Мордва Кармалка торак пунктында 2029 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Мордва Кармалка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Кармалка авыл җирлегенең Мордва Кармалка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, МХОда катнашучыларның гаиләләреннән тыш, 2026 елда 1000 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1 ) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Мордва Кармалка авылы территориясен коры-сары һәм чүп үләннәреннән чаптыру, Мордва Кармалка авылы территориясен сөрү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мордва Кармалка авылындагы юлларны кардан чистарту, Мордва Кармалка авылының Геодезия урамындагы юлны вак таш белән капланган чокырларны ремонтлау);

3) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (Мордва Кармалка авылында суүткәргеч өзеклекләрен бетерү).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мордва

Кармалка ав., Геодезия ур., 38а йорт (административ бина), Таулы ур., 33 йорт (мәдәният йорты бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/), кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Кармалка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы В.Д.Фәтхетдинова